Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XL-12**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 28 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 5 августындагы LIV-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әлеге мәгълүматларны бозуы алай ук мөһим булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 5 августындагы LIV-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әлеге мәгълүматларны бозуы алай ук мөһим булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү Тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Тәртип тексты буенча «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Ф.М. Вафинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов